РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
**Малосалтыковского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Б. Урманче, 9 с. Малые Салтыки, 422812
тел. (8277)36-2-18, факс: (8277) 36-2-18
ОКПО 9405059 ОГРН 1061672018033
ИНН/КПП 1622004757/1162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Кече Салтык**
**авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Б.Урманче урамы, 9,Кече Салтык авылы, 422812,
тел. (8277)36-2-18, факс: (8277) 36-2-18
ОКПО 9405059 ОГРН 1061672018033
ИНН/КПП 1622004757/1162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**2018елның 24 сентябре** **№ 8**

**Җирле референдум уздыру инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум уздыруны түбәндәге мәсьәлә буенча башлап җибәрергә:

«2019 елда «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә сез килешәсезме:

***җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**

***җирлекнең торак пунктлары чикләрендә территорияләрне төзекләндерүне оештыру;**

***ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту**

ӘЙЕ ЮК ";

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманче ур., 9 йорт, Мәдәният йорты бинасы;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов ур., 9, авыл китапханәсе мәдәният йорты бинасында, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**А.Г. Җиһаншин**